**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 30 декабрь № 1073

г. Казань

Мәгариф өлкәсендә бирелгән дәүләт йөкләмәләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын раслау хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 ел, 22 февраль, ТРЗ-15 нче Татарстан Республикасы Законының 8 статьясын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча бирелгән дәүләт йөкләмәләрен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру турында хисап формасын (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча бирелгән дәүләт йөкләмәләрен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын тутырганда барлыкка килә торган сорауларны аңлату эшләрен оештырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\1073.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 30 декабрь, 1073 нче
карары белән расланды

**Форма**

**________елның ____ кварталы өчен**
**белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча бирелгән дәүләт йөкләмәләрен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру турында хисап**

| Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге исеме | Белем бирү оешмаларында уку-укыту-методик эшчәнлек торышын комплекслы өйрәнү максаты белән үткәрелгән тикшерүләр саны[1] | Гомуми белем бирү оешмаларында методистлар үзләре җавап биргән юнәлешләр буенча кергән дәресләр, дәрестән тыш укулар, түгәрәкләр саны[1] | Гомуми белем бирүнең федераль дәүләт мәгариф стандартларын тормышка ашыру кысаларында белем бирү оешмалары базасында үткәрелгән муниципаль дәрәҗәдәге методик чаралар (семинарлар, практикумнар, конференцияләр, мастер-класслар, түгәрәк өстәлләр һ.б.ш.) саны[1] | Дәүләт йомгаклау аттестациясенә әзерлек кысаларында белем бирү оешмалары базасында үткәрелгән муниципаль дәрәҗәдәге методик чаралар саны[1] | Милли мәгарифне үстерү кысаларында белем бирү оешмалары базасында үткәрелгән муниципаль дәрәҗәдәге методик чаралар саны[1] | Җирле үзидарә органына бирелгән акча, мең сум[2] | Җирле үзидарә органына күчерелгән акча, мең сум[2] | Җирле үзидарә органы тарафыннан башкарылган чыгымнар, барлыгы, мең сум[2] | Хисап чоры ахырына файдаланылмый калган акча, мең сум[2] |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | |

Квартал хисабы

Җирле үзидарә органы җитәкчесе ________________________________
М.У. (Ф.И.Ат.ис., имзасы, дата)

________________________________________

[1] Белем бирү оешмасының исеме, тикшерү көне күрсәтелә.
[2] IV квартал йомгаклары буенча тутырыла.